ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**<u>2022 елның 24 феврале</u>** **Чистай шәһәре** **№ <u>125</u>**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 93 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 2377-р номерлы, 2021 елның 20 гыйнварындагы 68-р номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2022 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау» 2 нче кушымтасын 1,2,3,4 пунктлар белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы П.Б. Емельянов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 24 февралендәге
125 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елга республика бюджеты акчаларыннан финанслау (мең сум)

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | ел дәвамында | 595,72 |
| 2 | Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә түләүләр | ел дәвамында | 20,00 |
| 3 | Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчыларга-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүләр | ел дәвамында | 1800,00 |
| 4 | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физик-мәдәни спорт оешмалары командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында, хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | 273,20 |